ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТУРИЗМУ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТУРИСТЛЫК БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

06.09.2017 Казан ш. № 140

Татарстан Республикасы Туристлык буенча дәүләт комитетының "Татарстан Республикасы Туристлык буенча дәүләт комитетында дәүләт граждан хезмәте вакант вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертелүгә) конкурс уздыру турында нигезләмә раслау турында" 2016 елның 15 сентябрендәге 87 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Туристлык буенча дәүләт комитетында дәүләт граждан хезмәте вакант вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертелүгә) конкурс уздыру турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

"Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте турында" 2004 елның 27 июлендәге 79-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Президентының "Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте вакант вазыйфасын биләүгә конкурс турында" 2005 елның 1 февралендәге 112 номерлы Указы, "Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында" 2003 елның 16 гыйнварындагы 3-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә

б о е р ы к   б и р ә м:

Татарстан Республикасы Туристлык буенча дәүләт комитетының "Татарстан Республикасы Туристлык буенча дәүләт комитетында дәүләт граждан хезмәте вакант вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертелүгә) конкурс уздыру турында нигезләмә раслау турында" 2016 елның 15 сентябрендәге 87 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Туристлык буенча дәүләт комитетында дәүләт граждан хезмәте вакант вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертелүгә) конкурс уздыру турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.2 пунктының икенче абзацында "бу вазыйфага карата" сүзләрен "бу вазыйфаны биләү буенча" сүзләренә алмаштырырга;

3.2 пунктындагы "вакант вазыйфага карата" сүзләрен "вакант вазыйфаны биләү буенча" сүзләренә алмаштырырга;

4.4 пунктында:

4.4.1 пунктчасында "бу вазыйфаны биләүгә дәгъва белдерүчегә карата куела торган таләпләр" сүзләрен "бу вазыйфаны биләү буенча квалификация таләпләре" сүзләренә алмаштырырга;

4.4.5 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"4.4.5. Конкурсның беренче этабының нәтиҗәсе булып билгеләнгән таләпләргә җавап бирә торган һәм конкурста алга таба катнашу өчен киңәш ителгән кандидатларның конкурс комиссиясе рәисе тарафыннан расланган исемлеге тора.";

4.4.10 пунктчасында "граждан хезмәте вазыйфасына карата" сүзләрен "граждан хезмәте вазыйфасын биләү өчен" сүзләренә алмаштырырга;

4.7 пунктындагы "вакант вазыйфага карата" сүзләрен "вакант вазыйфаны биләү буенча" сүзләренә алмаштырырга;

күрсәтелгән Нигезләмәнең текстында:

"кадрлар һәм юридик эш секторы" сүзләрен, тиешле килештә кулланып, "кадрлар һәм юридик эш бүлеге" сүзләренә алмаштырырга;

"дәүләт хезмәте өлкәсендә дәүләт мәгълүмат системасы" сүзләрен "Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәтенең кадрлар составы белән идарә итүнең бердәм мәгълүмат системасы" федераль дәүләт мәгълүмат системасы (http://www.gossluzhba.gov.ru)" сүзләренә алмаштырырга;

күрсәтелгән Нигезләмәгә 3 нче кушымтада:

1.1 пунктындагы "законнарда билгеләнгән таләпләргә туры килә торган" сүзләрен "законнар нигезендә билгеләнгән квалификация таләпләренә туры килә торган" сүзләренә алмаштырырга;

1.2 пунктының 10 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"10) моңа законлы нигезләүләр булмыйча, чакырылыш комиссиясе бәяләмәсе нигезендә аны хәрби хезмәтне үтәмәгән дип тану очрагында (контракт буенча хәрби хезмәт үтәгән гражданнардан кала), – күрсәтелгән бәяләмәне Татарстан Республикасы чакырылыш комиссиясенә шикаять кылу өчен билгеләнгән вакыт узганнан соң 10 ел эчендә, ә әгәр дә күрсәтелгән бәяләмә һәм (яисә) күрсәтелгән бәяләмәгә гражданинның шикате буенча Татарстан Республикасы чакырылыш комиссиясе карары судта шикаять ителгән булса, – күрсәтелгән бәяләмәне һәм (яисә) күрсәтелгән бәяләмәгә гражданинның шикаяте буенча Татарстан Республикасы чакырылыш комиссиясе карарын чыгарганда гражданинның хокуклары бозылмавы танылган суд карары законлы көченә кергән көннән соңгы 10 ел эчендә;";

2.1 һәм 2.2 пунктларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"2.1. Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте буенча һөнәри белемгә һәм стажга карата яисә белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча эшләү стажына карата квалификация таләпләре:

Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең барлык категорияләрендәге баш вазыйфалар – белгечлек, магистратура дәрәҗәсеннән ким булмаган югары һөнәри белемгә ия булу, дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларында

кимендә ике еллык дәүләт хезмәте стажына яки белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча кимендә өч еллык эш стажына ия булу;

Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең барлык категорияләрендәге әйдәп баручы вазыйфалар – югары һөнәри белемгә ия булу, граждан хезмәтенең өлкән һәм кече төркемнәрендәге вазыйфаларда кимендә бер еллык дәүләт хезмәте стажына яки белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча кимендә ике еллык эш стажына ия булу;

Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең "белгечләр" категориясендәге өлкән вазыйфалар – стажына карата таләпләр куелмыйча, югары һөнәри белемгә ия булу;

Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең "тәэмин итүче белгечләр" категориясендәге өлкән вазыйфалар – белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча эшләү стажына карата таләпләр куелмыйча, югары һөнәри белемгә ия булу.

Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте стажын билгеләгәндә шулай ук федераль дәүләт граждан хезмәтенең тиешле вазыйфалар төркемнәрендәге вазыйфаларда, хәрби вазыйфаларда һәм бүтән федераль дәүләт хезмәте вазыйфаларында, дәүләт вазыйфаларында, муниципаль вазыйфаларда, тиешле вазыйфа төркемнәренең муниципаль хезмәт вазыйфаларында, бүтән вазыйфаларда эшләү стажы федераль законнарга туры китереп исәпкә алына.

Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте яисә белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча эшләү стажына карата шушы пунктның икенче һәм өченче абзацларында күрсәтелгән квалификация таләпләре, Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларының төп һәм әйдәп баручы төркемнәрендәге "белгечләр" категориясе вазыйфаларын эшчәнлек юнәлешенә туры килә торган фәнни дәрәҗәгә ия булган затлар биләгәндә, Татарстан Республикасы Туристлык буенча дәүләт комитеты рәисе карары нигезендә исәпкә алынмаска мөмкин.

Бик яхшы билгеләренә белгеч яисә магистр дипломына ия булган затлар өчен диплом тапшырылган көннән башлап өч ел дәвамында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең әйдәүче вазыйфаларын биләү буенча Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте стажына карата яисә белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча эш стажына карата квалификация таләпләре билгеләнә – Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте яисә белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча кимендә бер еллык эш стажы.

2.2. Вазыйфаи бурычларны үтәү өчен кирәкле булган белемнәргә һәм осталыкларга карата квалификация таләпләре Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәренең һөнәри хезмәт эшчәнлеге өлкәсенә һәм төренә карап, аның вазыйфаи регламентында билгеләнә. Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәренең вазыйфаи регламентында шулай ук белгечлегенә, әзерлек юнәлешенә карата Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфасын биләү өчен зарури булган квалификация таләпләре дә каралырга мөмкин.".

Рәис С.Е. Иванов